Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VIII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда "территорияләрдән" сүзеннән соң ", Тарлау авылы территориясен дә кертеп," сүзләрен өстәргә;


2) 4 статьяда:
а) җиденче абзацта "Котловка, " сүзеннән соң "Покровский," сүзен өстәргә;
б) унынчы абзацта "Покровский," сүзен төшереп калдырырга;

3) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның читтәге чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 4 (16) - 3 (17) | - Удмурт Республикасы |
| 3 (17) - 6 (215) | - Менделеевск муниципаль районы |
| 6 (215) - 8 (216) | - Удмурт Республикасы |
| 8 (216) - 23 (64) | - Менделеевск муниципаль районы |
| 23 (64) - 42 | - Тукай муниципаль районы |
| 42 - 35 (63) | - "Чаллы шәһәре" муниципаль берәмлеге |
| 35 (63) - 31 (62) | - Тукай муниципаль районы |
| 31 (62) - 38 (61) | - Түбән Кама муниципаль районы |
| 38 (61) - 4 (16) | - Мамадыш муниципаль районы |

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Алабуга шәһәре |
| 2 | Илмәт авыл җирлеге |
| 3 | Бехтерев авыл җирлеге |
| 4 | Олы Елово авыл җирлеге |
| 5 | Олы Качык авыл җирлеге |
| 6 | Олы Шүрнәк авыл җирлеге |
| 7 | Костенеево авыл җирлеге |
| 8 | Лекарево авыл җирлеге |
| 9 | Морт авыл җирлеге |
| 10 | Мурзиха авыл җирлеге |
| 11 | Поспелово авыл җирлеге |
| 12 | Иске Күклек авыл җирлеге |
| 13 | Иске Юраш авыл җирлеге |
| 14 | Танай авыл җирлеге |
| 15 | Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге |
| 16 | Яковлево авыл җирлеге". |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 91-ТРЗ